ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 март 2023ел. № 2093

Башкарма комитетның «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 29 октябрендәге 7120 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 29 октябрендәге 7120 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2022 елның 18 мартындагы 1438 номерлы, 2022 елның 7 октябрендәге 5360 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте һәм балаларны савыктыру» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына тәэмин итәргә: 2022 елда – 495,8 мең сум; 2023 елда – 500 мең сум; 2024 елда – 500 мең сум.»;

2) «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә:

«Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, датасы, номеры)» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, датасы, номеры) | «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының |

| | |
|---|---|
| | югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указы;<br>«Ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы турында» 2019 елның 17 августындагы 1067 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең «Дәүләт яшьләр сәясәте нигезләре» 2014 елның 29 ноябрендәге 2403 номерлы боерыгы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 27 декабрендәге 2950-р номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү концепциясе;<br>«Социаль активлык», «Патриотик тәрбия» федераль проектлары, «Мәгариф» милли проекты;<br>Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Законы;<br>Татарстан Республикасының «Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Законы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ихтыяри ярдәм хәрәкәтенә булышлык итү турында» 2012 елның 5 октябрендәге 830 номерлы карары;<br>Башкарма комитетның «2021 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен тормышка ашыру буенча чаралар планын раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 5667 номерлы карары |

«Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 ел (мең сум) | 2023 ел (мең сум) | 2024 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 495,8 | 500 000 | 500 000 | 1495,8 |
| | Федераль бюджет | – | – | – | – |
| | Республика бюджеты | – | – | – | – |
| | Башка чыганаклар | – | – | – | – |
| | Барлыгы | 495,8 | 500 | 500 | 1495,8 |

«Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 2024 елга чараларны тормышка ашыру хисабына планлаштырыла: белем бирү оешмалары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр базаларында ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү үзәкләре (ширкәтләре, берләшмәләре) тарфыннан ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп ителгән 7 дән 79 яшькә кадәрге гражданнарның гомуми санын 2024 елга кимендә 5% ка арттырырга |

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

| Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 1 нче ел мең сум | 2 нче ел мең сум | 3 нче ел мең сум | Барлыгы мең сум |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 495,8 | 500 000 | 500 000 | 1495,8 |
| Республика бюджеты | - | - | - | - |
| Федераль бюджет | - | - | - | - |

- 6 бүлектә 2 һәм 3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәһәрнең ихтыяри ярдәмчеләр берләшмәләренең ихтыяри ярдәм чараларының ведомствоара планын әзерләү һәм раслау;

3) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучы ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) берләшмәләренең реестрын алып бару;»;

- 7 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирүче индикаторлар

| Индикаторның исеме | Исәпләү формуласы | Чыганак |
|---|---|---|
| Белем бирү оешмалары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр базаларында ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү үзәкләре (ширкәтләре, берләшмәләре) тарфыннан ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп ителгән 7 дән 79 яшькә кадәрге гражданнарның гомуми саны:<br>2021 ел – 2 %<br>2022 ел – 3 %<br>2023 ел – 4 %<br>2024 ел – 5 % | $C = \frac{C1 \times 100\%}{C2}$<br><br>монда С1 – ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп ителгән халык саны;<br><br>С2 – 7 яшьтән 79 яшькә кадәрге халыкның гомуми саны (агымдагы елга статистика мәгълүматлары буенча) | Кварталлык аналитик хисаплар:<br>Башкарма комитетның мәгариф идарәсе;<br>Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе;<br>Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәдәният идарәсе;<br>Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе;<br>Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе;<br>Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе;<br>Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе (алга таба – идарәләр)»; |

3) «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасына 1 нче кушымтаны, 1 нче кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә;

4) «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасына 2 нче кушымтаны, 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 24 мартындагы
2093 номерлы карарына
1 нче кушымта

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасына
1 нче кушымта

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралары буенча финанслау

| № т/б | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткече | | | | Финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2021 ел база | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2022 ел мең сум | 2023 ел мең сум | 2024 ел мең сум |
| Программаның максаты: милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, төрле яшьтәге гражданнарның массакүләм оештырылган ихтыяри ярдәм (волонтерлык) хәрәкәтен үстерү | | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| Белем бирү оешмалары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр базаларында ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү үзәкләре (ширкәтләре, берләшмәләре) тарфыннан ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп ителгән 7 дән 79 яшькә кадәрге гражданнарның гомуми саны | | | | | | 2% | 3 % | 4 % | 5 % | - | - | - |
| 1. Халыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуга мотивация формалаштыру һәм ихтыяри ярдәмченең уңай имиджын булдыру | | | | | | | | | | | | |
| 1. | «Игелек чыганагы» ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары конкурсы үткәрү | | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Чараларда катнашучылар саны, кеше | - | 30 | 30 | 30 | 80 | 80 | 80 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | «Халыкка игелек» PR-проекты үткәрү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Басма материаллар саны, данә | - | 400 | 400 | 400 | 20 | 20 | 20 |
| 3. | Социаль билбордлар әзерләп һәм шәһәр проспектларында урнаштырып, «Игелекле проект» социаль реклама конкурсы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Билбордлар саны, данә | 2 | 5 | 5 | 5 | 47,5 | 50 | 50 |
| | | | | Дипломнар/ сертификатлар саны, данә | - | 50 | 20 | 20 | | | |
| 4. | Шәһәрнең ихтыяри ярдәм (волонтерлык) хәрәкәте атрибутикасын эшләү һәм әзерләү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Атрибутика саны, данә | 36 | 200 | 80 | 80 | 119,6 | 80 | 80 |
| 2. Ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм профессионализмын арттыруда ярдәм күрсәтү, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) идеяләренә һәм проектларына булышлык итү | | | | | | | | | | | |
| 5. | «Ихтыяри ярдәмчеләр мәктәбе» проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше | - | 100 | 120 | 120 | 10 | 30 | 30 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Ел саен үткәрелә торган ихтыяри ярдәмчеләр форумы үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше | - | 100 | 120 | 120 | 59,6 | 70 | 70 |
| 7. | «Елның ихтыяри ярдәмчесе» шәһәр конкурсы оештыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше | - | 30 | 40 | 40 | 39,4 | 50 | 50 |
| 8. | Бөтендөнья ихтыяри ярдәмчеләр көненә багышланган «Ихтыяри ярдәмчеләр көне» шәһәр чарасы үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше | - | 300 | 300 | 300 | 89,7 | 90 | 90 |
| 9. | Ихтыяри ярдәмчеләрне транспорт грантлары белән тәэмин итү | Башкарма комитетның финанс идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Транспорт грантлары саны, данә | - | 100 | 50 | 50 | 30 | 30 | 30 |
| барлыгы: | | | | | | | | | 495,8 | 500 | 500 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Л.Р. Абдуллина

Башкарма комитетның
2023 елның 24 мартындагы
2093 номерлы карарына
2 нче кушымта

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасына
2 нче кушымта

Программа чаралары

| № т/б | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Программа чараларын башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Яр Чаллы шәһәрендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык) хәрәкәтенең норматив-хокукый базасын һәм инфраструктурасын үстерү | | | | |
| 1. | Шәһәр оешмалары базасында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре төзү һәм аларның эшчәнлеге | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе | Башкарма комитетның структур бүлекчәләре базасында ихтыяри ярдәмнең (волонтерлыкның) барлык юнәлешләре буенча яңа отрядлар төзү:<br>- мәгариф идарәсе – мәгариф өлкәсендә, гражданлык-патриотик тәрбия бирү өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр отрядлары, сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикле ихтыяри ярдәмчеләр отрядлары (инклюзив ихтыяри ярдәм), табигатьне саклау һәм экологик агарту өлкәсендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык), медиаволонтерлык;<br>- физик культура һәм спорт идарәсе – спорт өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр, вакыйгалар волонтерлыгы (зур, әһәмиятле вакыйгалар һәм чаралар); |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | - мәдәният идарәсе – мәдәният өлкәсендә ихтыяри ярдәм;<br>- шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе – территорияләрне төзекләндерү өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр, экология һәм табигатьне саклау өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр;<br>- архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе – шәһәр мохитен һәм туристлык эшчәнлеген үстерү өлкәсендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык) ;<br>- гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе – эчке эшләр органнарына ярдәм күрсәтү өлкәсендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык), гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр |
| 2. | Волонтерларны, шул исәптән спортчыларны, профессиональ хезмәткәрләрне, физик культура һәм спорт өлкәсендә тәрбияләнүчеләрне физик культура һәм спорт өлкәсендәге чараларга җәлеп итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | Физик культура һәм спорт чараларын оештыру һәм/яки үткәрү, шул исәптән сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар арасында, сәламәт яшәү рәвешен, физик культураны һәм спортны пропагандалау |
| 3. | Волонтерларны, шул исәптән мәдәният өлкәсе хезмәткәрләрен һәм тәрбияләнүчеләрне мәдәният өлкәсендәге чараларга җәлеп итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Волонтерлар катнашында мәдәният өлкәсендә массакүләм чаралар оештыру һәм / яки үткәрү |
| 4. | Ихтыяри ярдәмчеләрне мәгариф һәм яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларга, шул исәптән гомуми белем бирү оешмалары базасында волонтер үзәкләрен формалаштырганда, мәгариф һәм яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен һәм тәрбияләнүчеләрне ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) өлкәсендә чаралар оештыру һәм / яки үткәрү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү буенча аналитик хисап бирү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Айлык хисаплар һәм аналитик еллык хисап тапшыру |
| 6. | Өстәмә белем бирү учреждениеләре базасында ихтыяри ярдәмчеләрне (волонтерларны) укытуга юнәлдерелгән өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруны оештыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Балалар һәм яшүсмерләр өчен дәресләр үткәрү |
| 7. | Эшчәнлектә катнашучы ихтыяри ярдәмчеләргә (волонтерларга) психологик ярдәм оештыру һәм күрсәтү һәм психологик реабилитацияләүдә булышлык итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Консультацияләр үткәрү |
| 2. Халыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуга мотивация формалаштыру һәм ихтыяри ярдәмченең уңай имиджын булдыру | | | | |
| 8. | Ихтыяри ярдәмнең (волонтерлыкның) төрле юнәлешләре буенча ачык лекторийлар оештыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү | Ел саен ачык лекторийлар үткәрү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | |
| 9. | Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) чараларын яктырту өчен шәһәр массакүләм мәгълүмат чараларын (телевидение, радио, газеталар һ. б.) җәлеп итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Ел саен шәһәрнең рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылган кимендә 50 мәкалә |
| 10. | Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) чараларында катнашучыларга рәхмәт хатлары җибәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр | Ел саен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | |
| 11. | Ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) өчен Башкарма комитет карамагындагы оешмалар тарафыннан оештырыла торган мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларына чакыру билетлары бирү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Ел саен |
| 12. | Волонтерларның үз эшчәнлеге юнәлеше буенча ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) массакүләм шәһәр, республика, Бөтенроссия чараларында катнашуын тәэмин итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Үз эшчәнлеге юнәлеше буенча ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) шәһәр, республика, Бөтенроссия чараларында катнашуы |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы

Л.Р. Абдуллина